ПӘНҖЕШӘМБЕ
4 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 3 (5803)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат кузәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

РАЙОН СОВЕТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕ СЕССИЯЛӘРЕ

Күп миллионлы совет халкы гаять зур шатлык һәм күтәренкелек белән хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына иң алдынгы кешеләрне сайлады. Бу сайлаулар, дәүләт властының барлык органнарын Сталин Конституциясе нигезендә үзгәртеп коруны төгәлләде. Җирле Советларга сайлаулар, СССР, союзный һәм афтономияле республикаларның Верховный Советларына булган сайлаулар шикелле үк, зур оешканлык белән үтте, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин тирәсенә, Совет хөкүмәте тирәсенә хезмәт ияләренең гаять тыгыз тупланганлыгын тагын һәм тагын бер тапкыр күрсәтте.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайланган депутатлар үзләренең мактаулы һәм шул ук вакытта гаять җаваплы бурычларын үтәүгә зур дәрт белән керештеләр. 27—28 нче декабрьдә Казан шәһәрендәге район Советларының һәм 29—30 нчы декабрьдә Казан Шәһәр Советының беренче сессияләре булып үтте. Бу сессияләр, җирле Советлар эшендә әлегә кадәр күрелмәгән зур активлык белән, чын халык демократиясе астында үтте. Шулай ук республикабыздагы барлык авыл Советларының һәм поселкы Советларының беренче утырышлары да бердәмлек һәм оешканлык белән үтте. Бу беренче сессияләрдә, авыл һәм поселкы Советларының беренче утырышларында депутатлар үзләренә халык тарафыннан күрсәтелгән бөек ышанычны намус белән аклаячакларын, партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан куелган барлык бурычларны вактында һәм югары сыйфатлы итеп үтәү өчен большевикларча көрәшәчәкләрен бердәм рәвештә белдерделәр.

Кичә, 3 нче гыйнварда, республикабыздагы авыл районнарында хезмәт ияләре депутатларының район Советларының беренче сессияләре башланды.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советларының беренче сессияләре оештыру мәсьәләләрен хәл итү өчен җыелалар. Бу, гаять зур әһәмияткә ия булган җидди мәсьәлә. Сессияләр, район Советларының башкарма комитетлары составына халыкның көннән-көн үсеп бара торган сорауларына тулы җавап бирә алырлык, халык интересларын тулы акларлык талантлы оештыручыларны сайларга тиешләр. Район советларының бүлекләре җитәкчеләре итеп, даими комиссияләр җитәкчеләре һәм члennары итеп эшлекле, халык эше өчен, партиябез һәм хөкүмәтебез эше өчен бөтен көчләрен куеп эшләүче иптәшләр расланырга тиеш. Сессияләрдә оештыру мәсьәләләрен хәл кылганда, Советның теге яки бу эше өчен сайланачак кандидатурага аның әнә шул сыйфатларыннан чыгып якын килергә кирәк.

Район Советлары алдында хәзер аеруча зур һәм әһәмиятле бурычлар тора. Алар Сталинчыл өченче бишьеллык планда, партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарларында һәм шул съездда иптәш Сталин сөйләгән докладта ачык гәүдәләнгәннәр. Район Советлары, шул исәптән аларның депутатлары, үзләренең мактаулы бурычларын үтәүдә зур инициатива күрсәтергә тиешләр.

Һәр яктан культуралы район үзәге булдыру, урамнарны түзекләндерү, яшелләндерү, аларны асфальтлау, зур, якты һәм җылы мәктәпләр, клублар, уку өйләре һәм тораклар булдыру өчен көрәш—һәрбер район Советының, аның һәрбер депутатының игтибар үзәгендә булырга тиешле мәсьәләләрнең кайберләре менә шулар.

Коллективлашкан эре социалистик игенчелек хуҗалыгы оештырылу, колхозларны оешу-хуҗалык ягыннан ныгыту—авыл хуҗалыгының елдан-ел мул уңыш бирүен, колхозчыларның таза, культуралы тормышта яшәүләрен тәэмин итте. Колхоз крестьяннәренең материаль - көнкүреш хәлләре шулай итеп өзлексез яхшыра бара. Шуның нәтиҗәсендә, колхоз крестьяннәренең төрле товарларга, аерым алганда киң куллану товарларына булган сораулары артканнан-арта бара. Бу хәл, хезмәт ияләре депутатларының район Советлары алдына авыл районнарында җирле промышленность предприятиеләрен төзүне һәм эшләтә башлауны барлык чаралар белән җәелдереп җибәрүне таләп итә. СССР халык хуҗалыгы үсешенең өченче бишьеллык планы турында иптәш Молотов докладына буенча ВКП(б) ның XVIII нче съездында кабул ителгән резолюциядә болай диелә: „**Җирле промышленностьта** һәм промкооперациядә җирле чимал һәм җирле ягулык базасында вак предприятиеләр төзелешен җәеп җибәрергә". Моны үтәүне район Советлары большевикларча оештырырга һәм аны үтәргә тиешләр. Эшне шулай оештыру хезмәт ияләре массасын киң куллану товарлары белән вактында һәм системалы рәвештә тәэмин итүне хәл итәчәк.

ВКП(б) Үзәк Комитетының эше турында партиябезнең XVIII нче съездында сөйләгән отчет докладында иптәш Сталин эчке политика өлкәсендә партиянең бурычларын билгеләп, болай диде: „...Иң якындагы 3—4 ел эчендә гектарыннан уртача 12—13 центнер уңыш алып ел саен 8 миллиард пот ашлык җитештерүгә ирешү өчен, техник культуралар җитештерүне уртача 30—35 процентка арттыру өчен, сарыклар һәм дуңгызлар санын ике өлеш, мөгезле эре терлекләр санын 40 процент чамасына, атлар санын 35 процент чамасына арттыру өчен игенчелегебезнең һәм терлекчелегебезнең күтәрелүен тагын да җәелдерергә". Район Советлары иптәш Сталинның шушы күрсәтмәсеннән чыгып үзләренә конкрет чаралар билгеләргә һәм аны үтәү көрәшенә хезмәт ияләренең киң массасын тупларга тиешләр. Моның өчен алар авыл советларына, колхоз правлениеләренә барлык ярдәмне күрсәтергә һәм большевистик җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр. Хәзер безнең республикабызның колхозлары өченче бишьеллыкның өченче язы алдында торалар һәм аны лаеклы каршылау өчен хәзерләнәләр. Район Советлары бу язга барлык колхозларның да большевикларча хәзерләнүләрен тәэмин итү өчен кирәк булганның барсын да эшләргә тиешләр.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советлары алдында торган иң әһәмиятле һәм гаять күп эшләрнең кайберләре әнә шулар. Бу бурычлар бары тик район Советлары эшенә барлык депутатларны тартканда гына, Советларның даими комиссияләре үзләренең эшләрен большевикларча үтәгәндә генә, совет эшенә барлык активистларны, шул исәптән сайлаулар вактында үсеп чыккан активистларны киң күләмдә тартканда гына һәм депутатларның көндәлек эшенә сайлаучылар якыннан торып булышканда гына үтәләчәк. Моны һәрбер хезмәт иясе һәм һәрбер депутат исендә нык тотарга тиеш.

Хезмәт ияләре депутатларының район Советларының беренче сессияләре, һич шиксез, үзләренең бурычлары югарылыгында үтәр һәм район Советларының башкарма комитетларына иң булдыклы, иң эшлекле иптәшләрне сайлар. Безнең депутатларыбыз—халыкның җирле Советлардагы вәкилләре—сайлаучылар тарафыннан күрсәтелгән бөек ышанычны һәр вакыт намус белән акларлар!

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Иптәш В. А. ДЕКТЯРЕВКА Социалистик Хезмәт Герое исме бирү турында

Кызыл Армия коралларының аеруча әһәмиятле яңа үрнәкләрен уйлап табу һәм конструкцияләү эшендәге күренекле хезмәтләре өчен иптәш Василий Алексеевич **Дектяревка** Социалистик Хезмәт Герое исме бирергә һәм СССР ның югары бүләгенән—Ленин ордены тапшырырга һәм акчалата 50 мең сум премия бирергә.

ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Председателенең урынбасары А. БАДАЕВ.
ССР Союзы Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва. Кремль, 2 гыйнвар, 1940 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Беренче ранг командарм иптәш Б. М. Шапошниковны Ленин ордены белән бүләкләү турында

Кызыл Армиянең оператив эшенә җитәкчелек итү буенча уңышлы эшләре өчен Кызыл Армиянең Генеральный штабы начальнигы, беренче ранг командарм иптәш Борис Михайлович **Шапошниковны** Ленин ордены белән бүләкләргә.

СССР Верховный Советы Президиумының Председателе урынбасары А. БАДАЕВ.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва. Кремль, 31 декабрь, 1939 ел.

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

Генеральный Штабның һәм СССР Оборона Халык Комиссариатының Үзәк Идарәләренең командирларын, политработникларын һәм хәрби инженерларын бүләкләү турында

Кызыл Армия командованиесенең оператив заданиеләрен уңышлы үтәүләре өчен бүләкләргә:

„КЫЗЫЛ БАЙРАК" ОРДЕНЫ БЕЛӘН:

Икенче ранг командарм **Смородинов** Иван Васильевичны.

„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ" ОРДЕНЫ БЕЛӘН:

1. Комкор **Захаров** Матвей Васильевичны.
2. Комбриг **Беликов** Михаил Трофимовичны.
3. Комбриг **Гусев** Николай Ивановичны.
4. Комбриг **Василевский** Александр Михайловичны.
5. Комбриг **Иванов** Владимир Дмитриевичны.
6. Комбриг **Трубецкий** Николай Иустиновичны.
7. Комбриг **Уткин** Петр Васильевичны.
8. Полковник **Астапов** Александр Васильевичны.
9. Полковник **Глушков** Владимир Исаковичны.
10. Полковник **Казеи** Иван Анофриевичны.
11. Полковник **Смирнов** Дмитрий Ивановичны.
12. Полковник **Столяров** Василий Васильевичны.
13. Полковник **Четвериков** Николай Ивановичны.
14. Полковник **Шевченко** Федор Ивановичны.
15. Полковой комиссар **Москвин** Дмитрий Михайловичны.
16. Беренче ранг хәрби инженер **Волосок** Иван Павловичны.
17. Беренче ранг хәрби инженер **Патапов** Николай Ивановичны.
18. Беренче ранг хәрби инженер **Шепенников** Яков Ивановичны.
19. Беренче ранг интендант **Трегубенко** Алексей Максимовичны.
20. Майор **Боровик** Михаил Ивановичны.
21. Майор **Клеменко** Александр Яковлевичны.
22. Майор **Кузнецов** Дмитрий Павловичны.
23. Майор **Постников** Николай Восильевичны.
24. Майор **Шишкин** Федор Михайловичны.
25. Батальонный комиссар **Будилев** Иван Васильевичны.
26. Икенче ранг хәрби инженер **Болятко** Виктор Анисимовичны.
27. Икенче ранг хәрби инженер **Выселков** Иван Акимовичны.
28. Капитан **Маланьин** Константин Афанасьевичны.
29. Өлкән лейтенант **Пенин** Павел Александровичны.
30. Литограф **Данилов** Степан Ивановичны.

„ХЕЗМӘТТӘГЕ БАТЫРЛЫК ӨЧЕН" МЕДАЛЕ БЕЛӘН:

1. Полковник **Бычков** Иван Тихоновичны.
2. Полковник **Дементьев** Степан Михайлович
3. Беренче ранг интендант **Парилов** Иван Андреевичны.
4. Майор **Красковец** Михаил Алексеевичны.
5. Икенче ранг интендант **Груздев** Михаил Александровичны.
6. Икенче ранг хәрби врач **Хилько** Александр Иосифовичны.
7. Капитан **Гончар** Корней Леонтьевичны.
8. Капитан **Соломеев** Петр Петровичны.
9. Капитан **Сакович** Михаил Петровичны.
10. Өченче ранг хәрби инженер **Павлов** Михаил Васильевичны.
11. Өченче ранг интендант **Борисов** Федор Васильевичны.
12. Өченче ранг интендант **Власов** Алексей Петровичны.
13. Өченче ранг интендант **Новажилов** Яков Николаевичны.
14. Өченче ранг интендант **Федәров** Константин Федоровичны.
15. Өлкән лейтенант **Агапов** Михаил Никифировичны.
16. Өлкән лейтенант **Храмцовский** Константин Ивановичны.
17. Кече командир **Калужский** Яков Николаевичны.

СССР Верховный Советы Президиумының Председатель урынбасары А. БАДАЕВ.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва. Кремль, 31 декабрь, 1939 ел.

Казан депосының атаклы машинисты иптәш И. И. Ерин СССР Верховный Советы Президиумының 1939 нчы ел 23 нче ноябрьдәге указы буенча „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән бүләкләнде. Хәзер иптәш Ерин Казанда узловой партком секретаре булып эшли.

И. Галиев фотосы.

РЕСПУБЛИКА ПОЧЕТ ТАКТАСЫ

Тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауда отлично күрсәткечләр биргән алдынгылар һәм стахановчылар ВКП(б) райкомнарының һәм хезмәт ияләре депутатлары район советлары башкарма комитетларының күрсәтүләре буенча республика Почет Тактасына кертеләләр:

1. Ворошилов районының **Нөркәй МТС** ы—1939 нчы елның 23 нче декабренә—хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар көненә тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауны тулысынча төгәлләде (МТС директоры иптәш Булатов, директорның политик эшләр буенча урынбасары иптәш Садыков, МТС ның өлкән механигы иптәш Гафиуллов).

2. Нөркәй МТС ының трактор бригадаларында эшне үрнәк булырлык итеп оештырган һәм югары хезмәт җитештерүчәнлеге биргән трактор бригадалары бригадирлары Галиәхмәт **Галиев**, Вәли Салахов, Мансур **Хөсәинев** һәм Гайсә **Мөхәммәтҗанов** иптәшләр.

3. Нөркәй МТС ының эшләп чыгару нормасын 200 дән 300 процентка кадәр үтәгән тракторчылары Әхмәтша **Фарухшин**, Гали Фәхреттинов, Низам **Хөснеттинев** һәм Мәхмүзә **Галиәхметова** иптәшләр.

4. Нөркәй МТС ының тракторларга ремонт ясауда норманы 200 дән 300 процентка кадәр үтәгән тимерчесе Габдулла **Дәүләтев** һәм слесаре Әхтәм **Шәйхеттинев** иптәшләр.

5. Биләр районы, Зур Поляна МТС ының трактор бриагадасы бригадиры Юсуф иптәш **Хәлиуллин**. Ул тракторларга һәм тагылма машиналарга ремонт ясауны 1939 нчы елның 10 нчы декабренә тулысынча төгәлләде.

ЯҢА ЕЛНЫҢ БЕРЕНЧЕ ЭШ КӨНЕ ЙОМГАКЛАРЫ

Орджоникидзе исемендәге завод

Серго Орджоникидзе исемендәге заводның күп кенә стахановчылары яңа елның беренче эш көнен—2 нче гыйнварны хезмәтнең җитештерүчәнлеген күтәрү һәм яхшы сыйфатлы продукция эшләп чыгару белән билгеләп үттеләр.

Слесарь А. Капелько һәм А. Антонов иптәшләр 2 нче гыйнвар көнне агрегат җыю буенча задание алгач, аны үтәү белән яңа елның беренче эш көнендә хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә уңышлы адым ясадылар. Иптәш Капелько сменага бирелгән заданиясен 500 процент итеп, иптәш Антонов 300 процент итеп үтәде.

Слесарь А. Моисеев 2 нче гыйнвар көне заданиясен 350 процент итеп, шлифовальщик иптәш Ф. Куртаев 250 процент итеп үтәде.

Мастер иптәш Фәйзуллин группасы 2 нче гыйнвар көнне гаять әһәмиятле эш башкарды: группа 5 агрегат эшләп чыгарды. Техника контроле бүлеге ул агрегатларны яхшы итеп кабул итте.

Шәһәр Советы депутаты иптәш Х. Сибгатуллина заданиясен 300 процент, слесарь И. Данилов 250 процент итеп, Иванов иптәш 250 процент итеп үтәде.

Заводның стахановчылары яңа елның беренче эш көнен хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә гүзәл үрнәкләр күрсәтү белән үткәрделәр. Стахановчылар Москвадагы инструменталь заводы эшчеләренең хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен чакыруларына эш белән җавап бирделәр. Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүнең бишьеллык планын дүрт елда үтәү мөмкинлеген күрсәтәләр.

Язу машиналары заводы

Заводның иң яхшы стахановчылары 40 нчы елның беренче эш көне заданиесен арттырып үтәделәр. Отделка цехы көнлек планын 102,5 процент итеп үтәде.

Имальләүче иптәш Петропавловский көнлек заданиесен 140 процент, шлифовальщиклардан Фәрхутдинов һәм Галиуллин иптәшләр 150 шәр процент итеп үтәделәр.

Машиналарны эшкә җибәрүче механиклардан (җыю цехы) Кузнецов һәм Лаврентьев иптәшләр көнлек норманы 125 процент итеп, механика цехы слесаре иптәш Гурьянов 200 процент, Ногманов иптәш 150 процент итеп үтәделәр.

Казан Мехкомбинаты

Казан Мехкомбинатының коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә яңа елның беренче көнендә яхшы уңышларга ирештеләр. 2 нче гыйнвар көнне 2 нче мех фабрикасы үзенең көнлек заданиесен 112,6 процент итеп үтәде. Бу фабриканың отделка цехы көнлек заданиесен 120,7 процентка кадәр үтәүгә иреште. Аерым бригадалар тагын да яхшырак эшләделәр. Мәсәлән, Белова бригадасы көнлек планын 150 процент итеп, Зайкина һәм Абдуллина бригадалары 150 шәр процентан да арттырып үтәделәр.

Стахановчы иптәш Кашапова көнлек нормасын 170 процентка җиткерде. Ул 2 нче гыйнвар көнне 2.300 тире урнына 4.000 тире эшләп чыгарды.

Беренче мех фабрикасының сырейный цехы да 2 нче гыйнвар заданиесен 101 процент итеп үтәде. (ТатТАСС).

Ленинград Хәрби Округы Штабының оператив сводкасы

2 нче гыйнварда фронтта әйтерлек бер нәрсә дә булмады.

Һава начар булганлыктан безнең авиациябез күзәтү очышлары гына үткәрде.

Пропаганда һәм агитация работникларының өлкә күләмендәге киңәшмәсе

Бүген, кич 6 сәгаттә, Менжинский исемендәге клубта ачыла.

КӨН ТӘРТИБЕ:

1. Партия пропагандасын үзгәртеп коруның йомгаклары турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Матвеев доклады.

2. Халык арасында агитация-масса эшенең бурычлары турында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Долотказин доклады.

МАХСУС ТӨЗЕЛЕШ БУЕНЧА ХӨКҮМӘТ ЗАДАНИЕЛӘРЕН ҮТӘГӘНДӘ АЕРУЧА ЭШ КҮРСӘТКӘН РАБОТНИКЛАРНЫ БҮЛӘКЛӘҮ

СССР Верховный Советы Президиумының 1939 нчы елның 31 нче декабрьдәге указы белән, хөкүмәтнең махсус заданиеләрен үтәү буенча уңышлы эшләре өчен, 169 работник бүләкләнде.

422 нче номерлы төзелешнең төзү эшләре начальнигы Антон Никитович **Дешковец**, 5 нче номерлы төзелеш идарәсе начальнигы Михаил Степанович **Лешко**, 423 нче номерлы төзелеш начальнигы Василий Иванович **Павлов** һәм 5 нче номерлы төзелеш идарәсенең баш инженеры Виталий Дмитриевич **Селивохин** иптәшләр Ленин ордены белән бүләкләнделәр.

„Хезмәт Кызыл Байрагы" ордены белән 10 кеше, „Кызыл Йолдыз" ордены белән 13 кеше, „Почет Билгесе" ордены белән 44 кеше, „Хезмәттәге Батырлык өчен" медале белән 37 кеше һәм „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен" медале белән 61 кеше бүләкләнделәр. (ТАСС).

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИЯ МӘГАРИФЕ ЙОРТЫНДА

Партиянең Өлкә Мәгариф йорты партия пропагандасының куелышы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының карары нигезендә үзенең эшен яңа баштан үзгәртеп коруда зур гына уңышларга иреште. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнүчеләр өчен аерым лекция залы, индивидуаль уку залы, консультация бүлмәләре җиһазландырылган һәм күргәзмә материаллар белән тәэмин ителгән. 66 мең даннан артык китабы булган китапханәсе бар. ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләр тарафыннан марксизм-ленинизм классикларының әсәрләренә сорау көннән-көн үсә. Китапханәгә 100 дән артык төрле газета-журналлар алдырыла.

Партия Мәгарифе йорты „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнүчеләргә ярдәм итүдә лекцияләр һәм консультацияләр үткәрүне киң куллана. Узган елның 11 аенда штатлы һәм штаттан тыш лекторлар тарафыннан 282 лекция укылган. Бу лекцияләргә 46 меннән артык кеше катнашкан һәм 3.974 сораугa җавап бирелгән. Шулай ук групповой һәм индивидуаль консультацияләр дә үткәрелә.

Лекторлардан һәм консультантлардан Морозов, Мелещенко, Федин һәм Вахитов иптәшләр үзләренә тапшырылган лекторлык һәм консультантлык эшен намус белән үтиләр. Лекцияләрне һәм консультацияләрне аңлаешлы итеп үткәрәләр. Сорауларга ачык һәм тулы җавап бирәләр. Күргәзмә материаллардан тулы файдаланалар. Мондый консультацияләр марксизм-ленинизмны үзлекләреннән өйрәнүче иптәшләрне аерүча кызыксындыра. Нәтиҗәдә, күп кенә иптәшләр консультацияләргә системалы рәвештә йөриләр.

Партия Мәгарифе йорты, ВКП(б) Өлкә Комитеты белән берлектә, урыннардагы пропагандистлар өчен быел 5 тапкыр семинар үткәргән.

Ленин, Сталин һәм Киров иптәшләрнең тормыш һәм революцион көрәш юлларын тулы һәм ачык чагылдыра торган күргәзмәләр, шулай ук бөек Сталин Конституциясен иҗад итүгә 3 ел тулу көненә карата күргәзмә оештырылган. Җирле Советларга сайлауларга хәзерлек барышында сайлау участкысында эшләүче агитколлектив җитәкчеләре һәм агитаторлар өчен консультацияләр, иптәшләрчә беседалар системалы рәвештә үткәрелгән. Партия пропагандасын яңа баштан үзгәртеп коруда партия Мәгарифе йортының шактый гына уңышлыклары булу белән бергә, җидди генә кимчелекләре дә бар әле.

Партия Мәгарифе йорты урыннардагы парткабинетларның эшенә эшлекле ярдәм күрсәтергә тиеш иде. Ләкин бу ярдәмнең оештырылганы юк әле. Хәтта шәһәрдәге парткабинетлар белән дә тиешле элемтә булдырылмаган һәм бер нинди конкрет ярдәм күрсәтелми.

Партия Мәгарифе йортының эш планы канәгатьләнерлек үтәлмәгән. Һәр ай саен диярлек, өзелеп килгән. Партия Мәгарифе йорты җитәкчеләренең гаепләре аркасында Дөбъяз, Столбище һәм Питрәч районнарында октябрь, ноябрь һәм декабрь айларында план нигезендә үткәрелергә тиешле булган лекцияләр өзелгәннәр. Шулай ук Сталин районында (Казан шәһәре) планда күрсәтелгән ике лекция үткәрелмәгән.

Партия пропагандасы эшендәге бу җидди кимчелекләр һич кичекмәстән бетерелергә, урыннардагы парткабинетлар белән ныклы элемтә булдырылырга, марксизм-ленинизмны үзлекләреннән өйрәнүчеләргә эшлекле ярдәм күрсәтелергә тиеш.

Хаҗиев,
Әхмәдиев,
Сибатов.

Комсомолның җитәкче работниклары өчен ВЛКСМ Өлкә Комитеты янында оештырылган курсларда. РӘСЕМДӘ: курсантлар „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның VII бүлеге буенча дәрескә хәзерләнәләр. М. Солтанов фотосы.

МӘКТӘПЛӘРДӘ ДИНГӘ КАРШЫ ТӘРБИЯ ЭШЕН КӨЧӘЙТЕРГӘ

Дингә каршы тәрбия эше—ул, укучыларны коммунистик рухта тәрбияләүнең иң әһәмиятле тармагы. Бу эштә Сугышчан Алласызлар Союзының мәктәпләрдәге башлангыч оешмалары хәл иткеч урын тоталар. Сугышчан Алласызлар Союзы оешмалары булган мәктәпләрдә дингә каршы тәрбия эше системалы рәвештә алып барыла.

Сталин районындагы беренче номерлы урта мәктәптә Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмасы (җитәкчесе иптәш Сабирҗанова) дингә каршы тәрбия эшен яхшы гына оештырган. Укытучылар барсы да оешмада член булып торалар. Укучыларны членлыкка тарту буенча зур эш алып барыла. Нәтиҗәдә, уку елы башланганда 93 членнан торган бу оешмада хәзер членнар саны 153 кә җиткән.

Мәктәптә 1.400 дән артык укучы бар. Алар арасында дингә каршы тәрбия эше киң җәелдерелгән. ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң, башлангыч оешма ярдәме буенча, укучылар өчен дингә каршы темада 32 лекция укылган. Укытучылардан Гайфуллин, Таһирова, Туктамыйшева, Абдулхакова һәм Гәрәева иптәшләр бу эштә аеруча зур активлык күрсәтәләр. Алар үзләре укыта торган тарих һәм биология фәннәрен, дингә каршы тәрбия эшенә нык бәйләп алып баралар. Оешма җитәкчесе иптәш Сабирҗанова дингә каршы темаларда үзәк һәм өлкә газеталарда басылып чыккан материаллардан альбом оештырган. Бу материаллардан укытучылар нык файдаланалар.

Бу мәктәп ата-аналар арасында да дингә каршы тәрбия эшен план буенча алып бара. Соңгы алты ай вакыт эчендә генә дә ата-аналар өчен дингә каршы темада алты лекция укылган һәм аларда меңнән артык кеше катнашкан.

21 нче номерлы тулы булмаган урта мәктәптә дә дингә каршы тәрбия эше үрнәк булырлык итеп оештырылган. Анда бу эшкә пар оешма секретаре иптәш Ахунҗанов җитәкчелек итә. Ул тарих фәнен дингә каршы тәрбия эшенә бәйләп алып бара. Сайлауларга хәзерлек чорында гына да ул ата-аналар өчен 12 лекция укыган.

Бу мәктәпләрнең икесендә дә дингә каршы китаплар укучыларның сорауларын канәгатьләндерерлек санда булдырылган. Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмалары газета-журналларны җитәрлек санда алалар.

Сталин районындагы 51 нче номерлы тулы булмаган урта мәктәптә (директоры иптәш Шәрәфеттинев) эш бөтенләй башкача тора. Бу мәктәптә 800 укучы, 36 укытучы бар, партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары бар. Шуңа да карамастан, мәктәптә Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмасы да оештырылмаган. Укучылар һәм ата-аналар арасында дингә каршы тәрбия эше кампания төсендә генә алып барыла. Монда укучылар һәм ата-аналар өчен ураза һәм аның зарары турында ике тапкыр лекция укылган. Ураза ае үтеп киткәч дингә каршы тәрбия эше бөтенләй тукталган. Бу мәктәптә дингә каршы тәрбия эшенә җитәкчелек итүне берничә төрле нагрузкасы булган иптәш Маннаевага тапшырып, директор Шәрәфеттинев, партоешма секретаре Бурнашева һәм местком председателе Писсова иптәшләр бу эштән үзләре бөтенләй читләшкәннәр. Дингә каршы тәрбия эшенең гафу ителмәслек начар оештырылуы нәтиҗәсендә, кайбер укучылар арасында дини гореф-гадәтләрне үтәү фактлары да булган.

Районнардагы барлык мәктәпләрдә дә Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмаларын булдыру һәм алар ярдәме белән дингә каршы тәрбия эшен тагын дә көчәйтү турында Сугышчан Алласызлар Союзының район советы да (председателе иптәш Гайнуллин) җитәрлек кызыксынмый. Хәтта иптәш Гайнуллин Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмалары булган мәктәпләр белән элемтә дә тотмый һәм аларга бер төрле дә практик ярдәм күрсәтми.

Район советы барлык мәктәпләрдә дә Сугышчан Алласызлар Союзының башлангыч оешмаларын оештыруга һәм аларга конкрет җитәкчелек итүгә игтибар бирүен көчәйтергә тиеш.

С. Бәдгеттинев,
Г. Шәймөхәмәтов.

Дингә каршы пропаганда кадрлары

Сугышчан Алласызлар Союзының Татарстан Республика Советы Сугышчан Алласызлар Союзының район активы өчен өлкә күләмендә бер айлык курслар үткәрде. Курсларда 24 кеше укыды. Аларның күбесе авыл районнарыннан иде. Курсантлар 200 сәгатьлек курс үттеләр. Укытучылар итеп Казан шәһәренең квалификацияле фәнни көчләре тартылды. Лекцияләр үткәргәндә күргәзмә пособиеләрдән киң күләмдә файдаланылды. Үзәк тарих музеенә, Казан Дәүләт университетының зоология һәм биология музейләренә һәм башка урыннарга экскурсия ясалды.

Курсантлар курсның программасын үзләштерүдә зур тырышлык күрсәттеләр. Аларның күпчелеге укуларны яхшы билгесенә тәмамлады. Алар авылларга кайткач, дингә каршы пропаганда эшен җәелдерүдә, массаны коммунизм рухында тәрбияләүдә партия һәм комсомол оешмаларына якыннан торып ярдәм итүче булырлар.

Х. Салихов.

РӘСЕМДӘ: Красный Бор районы, Исәнбай авылының тулы булмаган урта мәктәп укытучысы Лотфулла иптәш Җамалеев марксизм-ленинизм классикларының әсәрләрен өйрәнү вактында. М. Шакиров фотосы.

УКЫТУЧЫ-АКТИВИСТ

Красный Бор районы, Исәнбай авылындагы тулы булмаган урта мәктәп укытучысы иптәш Лотфулла Җамалеев, узган елны хөкүмәтебез тарафыннан „Аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән бүләкләнде. Ул медальне алганда:

— Хөкүмәтебез тарафыннан бирелгән бу бөек бүләк миндә киләчәктә тагын да яхшырак эшләүгә яңа көч тудырды. Ленин—Сталин партиясе эше өчен, бөек халкым өчен көчемне кызганмыйча хезмәт итәрмен,—дигән иде.

Иптәш Җамалеев бу вәгъдәсен үзенең практик эше белән аклый, көннән-көн югарылыкка һәм алга омтыла. Ул үзе укыта торган география фәненнән 1939—40 нчы уку елының беренче чирегендә үк инде 100 процент өлгереш бирде. Уку елын югары күрсәткечләр белән тәмамлау өчен тырышып эшли. Ул җитәкчелек итә торган V нче „А“ классы өлгереш һәм йөреш ягыннан мәктәптә беренче урында бара. Бу классның укучылары арасында тәртип һәм чисталык нык саклана, алар мәктәпнең җәмагат эшенә актив катнашалар.

Иптәш Җамалеев 100 дән артык укучыны ПВХО значогына нормалар тапшыруга хәзерләде. Допризывниклардан значкистлар хәзерләү буенча да занятиеләрне системалы рәвештә үткәрә. Табигатьне өйрәнү буенча һәм халыкара хәл турында докладлар ясый. Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар вактында ул агитколлектив һәм консульпункт җитәкчесе булып эшләде.

Иптәш Җамалеев үзенең белемен күтәрү өстендә өзлексез эшли. Ул Казан Дәүләт Педагогия институты география факультетының III нче курсында читтән торып укый. „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н конспект төзеп өйрәнүне тәмамлады. Бу бөек тарихны өйрәнгәндә ул Лениннең һәм Сталинның күп кенә әсәрләрен укып чыкты. *М. Шакиров.*

Исәнбай авылындагы ТБУМ нең укыту бүлеге мөдире.

Яш коммунистларны без ничек тәрбиялибез

ВКП(б) ның XVIII нче съездыннан соң үткән вакыт эчендә, партиянең Тәтеш МТС ы янындагы башлангыч оешмасы 12 кешене ВКП(б) членлыгына кандидат итеп алды. Шулардан 10 кеше тракторчы һәм комбайнчы стахановчылар. Алар әле „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ дәресләге буенча үзлекләреннән эшли алырлык дәрәҗәдә түгелләр. Шунлыктан, партиянең башлангыч оешмасы кандидатларның барсын да партия укуларына тарту һәм аларны марксизм-ленинизм теориясе белән коралландыру өчен политграмота өйрәнү түгәрәге оештырды. Бу түгәрәктә барлыгы 20 кеше өйрәнә. Түгәрәктә ВКП(б) уставын, хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулар турындагы положениене өйрәндек.

Түгәрәктә өйрәнүче иптәшләр үтелгән материаллар буенча конспект төзиләр һәм яхшы үзләштереп баралар, занятиеләр зур күтәренкелек белән үтә.

Политграмота түгәрәгеннән тыш, агымдагы политиканы өйрәнү түгәрәге дә эшли. Анда һәрбер занятиедә кимендә 35 кеше була. Партия сафларына яңа алынган иптәшләргә партбюро тарафыннан аерым поручениеләр бирелә һәм аларның үтәлеше системалы тикшерелә.

Яш коммунистлар арасында политик тәрбия эшен яхшы кую нәтиҗәсендә, шактый уңышлы күрсәткечләргә ирешелде. Партия дисциплинасының куелышы яхшырды, партия җыелышлары зур активлык белән үтә, производствода коммунистларның авангардлык роле күтәрелде.

А. К. Атрясов.

КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР ЭШЕН ТАГЫН ДА ЯХШЫРТЫЙК

Урыннарга барып групповой һәм индивидуаль консультацияләр үткәрү „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнүчеләргә булышлык күрсәтүдә зур урын тота.

ВКП(б) ның Әлмәт райкомы янындагы парткабинет тарафыннан оештырылган күчмә консультацияләрнең саны әле җитәрлек булмаса да, алар ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә бик зур ярдәм иттеләр.

Күчмә консультацияләр оештыру эше июнь айларында башланып, шушы вакытка кадәр 16 урында үткәрелде, аларда 261 кеше катнашты. Моның өстенә август аеннан башлап, консультантлар урыннарга барып индивидуаль консультацияләр бирә башладылар һәм алар уңышлы алып барыла. Бу чор эчендә урыннарга барып 240 кешегә консультация бирелде.

Урыннарга барып үткәрелә торган индивидуаль консультациянең әһәмияте аеруча зур. Чөнки индивидуаль консультация вактында үзлегеннән укучы иптәшнең үзенә хас булган мәсьәләләр буенча консультация бирү белән бергә, аңа китап белән ничек эшләү, конспектны ничек язу һәм башкалар турында да методик күрсәтмәләр бирергә була һәм ул иптәшкә теоретик мәсьәләләрдә генә түгел, бәлки методик мәсьәләләрдә дә зур ярдәм итеп була.

Урыннарга барып үткәрелә торган консультацияләрне хәзерләү һәм оештыру ягына зур игтибар бирергә кирәк. Мондый консультацияләрне яхшы итеп оештыру өчен, иң беренче чиратта, консультантларның колхозлардагы партоешмалар белән якын элемтә дә булулары кирәк. Шуның нәтиҗәсендә, консультант ул оешмада „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“н үзлекләреннән өйрәнүче иптәшләр өчен кайсы бүлек буенча һәм нинди төп мәсьәләләргә карата консультация кирәклеген ачык белә ала. Менә шуңа күрә дә без күчмә консультацияләрнең эшен планлаштырганда, беренче чиратта, консультантлардан шушы нәрсәне таләп итәбез. Тик шул мәсьәлә ачыклашкач кына ул оешма өчен нинди бүлек һәм нинди төп мәсьәләләр буенча групповой консультация үткәрүне хәл итәбез. Хәзерлек эшенең беренче шарты булып әнә шул тора.

План нигезендә групповой консультациянең кайсы бүлек буенча һәм кайсы числода, кайсы сәгаттә булуын күрсәтеп, консультация үткәреләчәк партоешмага кимендә бер атна алдан хәбәр итәбез.

Күчмә консультацияләрне үткәрү планын төзү белән консультантлар да үзләре үткәрәчәк консультациягә ныклап хәзерләнәләр. Без консультантлардан консультациягә яхшы хәзерләнеп килүне, үзе үткәрергә тиешле булган бүлекләрне тирән итеп, барлык деталләренә кадәр өйрәнеп килүне таләп итәбез. Бу метод, һич шиксез, консультантка консультациянең сыйфатын күтәрүдә зур ярдәм итә.

„ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ буенча консультация алып бару өчен райком бюросы 6 консультант раслады. Бу консультантлар арасында эш бүлешкәндә кемгә, кайсы бүлек йөкләнгән булса, ул шул бүлекне тирәнтен өйрәнә һәм шул бүлек буенча консультация үткәрә. Бер үк бүлек буенча ике иптәш хәзерләнә. Чөнки кайбер сәбәпләр буенча берсе уздыра алмаса, аның икенчесе шул планда күрсәтелгән вакытта уздыра. Мәсәлән, минем үземә темаларны бүлгәндә групповой консультацияләр алып бару өчен, „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“ның IV, VI, IX, XI нче бүлекләре буенча хәзерләнү һәм шул бүлекләр буенча үткәрү йөкләнде. Шул ук бүлекләр тагын бер консультантка (иптәш Галиевкә) йөкләтелде. Димәк, бу бүлекләр буенча без ике кеше параллель үткәрәбез. Бу нәрсә, бер яктан, консультацияләрне яхшырак үткәрергә ярдәм итсә, икенче яктан теге яки бу сәбәпләр буенча беребез үткәрә алмасак, икенчебез үткәрүне тәэмин итә. Ә калган бүлекләр инде башка консультантлар арасында бүленгәннәр.

Күчмә консультацияләрне оештыру һәм аларны үткәрү өчен хәзерлек безнең районда әнә шулай алып барыла.

Күчмә групповой консультацияләрне үткәрү методы турында берничә сүз.

Консультант урыннарга яхшы хәзерләнеп һәм үтеләчәк тема буенча кирәкле булган күргәзмә материалларны алып бара. Консультациянең көне һәм темасы алдан билгеләнгән булганлыктан, күпчелек иптәшләр аңлашылып җитмәгән мәсьәләләр буенча сораулар хәзерләп килиләр.

Консультант иң элек консультациянең тәртибе һәм кайсы бүлек буенча булачагы турында 10—15 минут эчендә аңлаткач, консультациягә килүчеләр үзләренә аңлашылып җитмәгән мәсьәләләр буенча сораулар бирәләр. Аннан соң консультант үзенә бирелгән сорауларны группаларга бүлә һәм ул сорауларга карата үзенең җавабын планлаштыра. Сорауларны группаларга бүлгәндә, аерым терминнар турындагы сорауларны иң ахырга калдыра. Төп мәсьәләләр буенча аңлатып бетергәннән соң, терминнар тәртибендәге сорауларга җавап бирә.

Консультациягә килгән иптәшләр тарафыннан бирелгән сорауларны группаларга бүләбез, системага салабыз. Мәсәлән, мин үзем әле декабрь аенда гына „Кыскача курс“ ның IV нче бүлеге буенча Габдрахман авылында консультация үткәрдем. Миңа түбәндәге сорауларны бирделәр:

1. Маркснең философик материализмын ничек аңларга.
2. Диалектик методны мисаллар белән ничек аңлатырга кирәк.
3. Отзовистлар кемнәр.
4. Идеалистик караш нәрсә ул.
5. Саннан сыйфатка күчүне мисаллар өстендә ничек аңлатырга.
6. Метафизик караш нинди караш ул.
7. Эшләп чыгару мөнасәбәтләре эшләп чыгару үсешенә кай вакытта һәм ничек тәэсир итәләр.
8. Алла эзләүчеләр кемнәр.
9. Рус махистлары турында аңлатыгыз әле.

Болардан башка 8 сорау аерым терминнар турында иде.

Бу сорауларны группаларга бүлеп, түбәндәге план буенча консультация үткәрелде:

1. Марксизмның 3 чыганагы һәм 3 состав кисәге турында.
2. Диалектика һәм метафизика һәм диалектик методның төп законнары турында.
3. Маркснең философик материализмының төп билгеләре турында.
4. Рус махистларының карашлары һәм аларны тар-мар итүдә Лениннең „Материализм һәм эмпириокритицизм“ дигән әсәренең әһәмияте турында.
5. Җитештерүнең өч үзенчәлеге турында.

Менә шушы план буенча консультация бирү 2 сәгать 30 минут дәвам итте.

Консультацияне уздыруны без әнә шулай алып барабыз.

Күчмә консультацияләрне (групповойлары да, индивидуаль консультацияләр дә) оештыру һәм яхшы итеп хәзерләү мәсьәләсендә күп кенә кимчелекләр бар әле. Күчмә консультацияләрне оештыруда партиянең башлангыч оешмасы секретарьларының роле бик зур. Әгәр дә партоешма секретарьлары консультацияне оештыруга зур әһәмият бирсәләр, һич шиксез, ул консультациягә урындагы актив яхшы хәзерләнә һәм консультация зур активлык белән үтә, аның эчтәлеге дә яхшы була.

Мәсәлән, 8 нче декабрьдә Габдрахман авылында консультация үткәрдем. Бу авылдагы партоешма секретаре иптәш Баязитованың моңа нык игтибар бирүе нәтиҗәсендә, урындагы актив консультациягә яхшы хәзерләнгән иде. Шул ук тема буенча 18 нче декабрьдә Тайсуган авылында консультация үткәрергә туры килде. Бу авылдагы партоешма секретаре иптәш Әхметованың консультациягә хәзерлек эшенә җитәрлек игтибар бирмәве нәтиҗәсендә, консультациягә иптәшләр бер сәгать соңга калып җыелдылар һәм күпчелек иптәшләр консультациягә бөтенләй хәзерлексез килгәннәр иде. Шуның өчен бу консультациянең сыйфаты яхшы булмады.

Урындагы партоешмалар күчмә консультацияләрне оештыру ягына нык игтибар биргәндә, консультацияләрнең сыйфаты һич шиксез, тагын да яхшырачак һәм марксизм-ленинизм нигезләрен үзлекләреннән өйрәнүчеләргә эш урыннарына барып ярдәм итү эше тәэмин ителәчәк.

Хәбир Шакиров.

ВКП(б) райкомының пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире.

ХЕЗМӘТ ҖИТЕШТЕРҮЧӘНЛЕГЕН ҮСТЕРҮ БУЕНЧА БИШЪЕЛЛЫК ЗАДАНИЕСЕН ДҮРТ ЕЛДА ҮТИК

Советлар Союзындагы машина төзелеше заводларының барлык эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженер-техник работникларына һәм хезмәткәрләренә Москвадагы инструменталь заводы коллективының мөрәҗәгате

Кадерле иптәшләр!

Большевистик партиябезнең XVIII нче съезды гаять зур бурычны—аеруча алга киткән капиталистик илләрне кыска срок эчендә экономик яктан да куып җитү һәм узып китү бурычын куйды. Бу бурычны хәл итү өчен 10—15 ел кирәк. ВКП(б) ның XVIII нче съезды трибунасыннан иптәш Сталин болай диде: „Бездә хезмәтнең җитештерүчәнлеге никадәр югары булса, бездә производство техникасы никадәр яхшыра барса, бу иң әһәмиятле экономик бурычны шул кадәр тизрәк үтәргә мөмкин булачак, бу бурычны үтәү срокларын шул кадәр күбрәк кыскартырга мөмкин булачак".

Иптәш Сталинның бу күрсәтмәсе безгә өченче бишьеллык планны үтәү өчен алга таба барырга тиеш булган юлны яктырта.

СССР ның төп экономик бурычын хәл итүне барлык чаралар белән тизләтү безнең үзебезгә, безнең хезмәткә омтылышыбызга, энергиябезгә, төрле тармакларда эшләүче һәрбер совет патриотының хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү темпларына бәйләнгән.

Халык хуҗалыгын техника ягыннан коралландыруда машина төзелешенә алдынгылык роле йөкләтелгән. Шунлыктан безгә, машина төзүчеләргә, халык хуҗалыгының башка тармакларын уңышлы үстерү өчен зур җаваплылык йөкләнә, без социалистик җәмгыяткә лаеклы булган югары хезмәт җитештерүчәнлеге өчен көрәштә алда барырга тиешбез.

Өченче бишьеллыкның икенче елы социалистик Ватаныбызга яңа уңышлар китерде. 1939 нчы ел промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү өлкәсендә зур резервлар барлыкны күрсәтте. 1939 нчы елның 6 нчы ноябрендә Москва Советының тантаналы утырышында ясаган докладында иптәш В. М. Молотов болай диде:

„Үткән елны безнең промышленностьта хезмәт җитештерүчәнлеге 11 процентка арткан булса, быел бездә хезмәт җитештерүчәнлеге билгеләнгән планнан артыграк, ягни 17 процентка артты. Бу, үткән елга караганда шактый артык булган промышленность производствосы күләмен шул ук составтагы һәм хәтта бераз азырак составтагы эшчеләр белән үти алдык дигән сүз. Илебездә эшче кадрлары җитешмәгәндә моның гаять яхшы әһәмияте бар".

Безнең Москвадагы инструменталь заводы 1939 нчы елны производствода зур гына уңышларга ирешде.

Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышка кушылып, безнең коллектив еллык программаны срогыннан алда үтәргә һәм планнан тыш 5 миллион сумлык югары сыйфатлы инструмент бирергә йөкләмә алган иде. **Без үзебезнең сүзебездә тордык—еллык план 1 нче ноябрьгә үтәлде.** Планнан тыш завод 5 миллион сумлыктан артык инструмент эшләп чыгарды.

1939 нчы елның 11 ае эчендә продукция эшләү, үткән елның шул ук чоры белән чагыштырганда, 39 процентка артты. Болай арттырып үтәүгә без тулысынча хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү исәбенә ирештек. Хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча еллык задание 11 ай эчендә 19 процентка арттырып үтәлде.

Безнең стахановчыларыбыз һәм ударникларыбыз, эшләп чыгарудагы искергән нормаларны ватып, технология процессына әһәмиятле төзәтмәләр кертәләр, техниканы революционлаштыралар. Заводыбызның инструментчылары — лекаль эшләрен механикалаштыруның инициаторлары булып торалар. Бездә лекаль эшләренең шактый өлеше механикалаштырылды. Шуның аркасында күп кенә операцияләрдә хезмәт җитештерүчәнлеге 3—5 тапкыр үсте. Вак тешле калибрларны доводкалауда кулланыла торган кул хезмәте кимеде. Бу чара хезмәт җитештерүчәнлеген 3—4 тапкырга күтәрде.

Хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрә торган шушындый чаралар күп үткәрелде.

Күп станокларда эшләүне һәм бер үк вакытта берничә профессиядә эшләүне кертү хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да югары күтәрәләр. Мәсәлән, протяжкалар цехының фрезер участкысында стахановчылардан Тонгашев, Верендеев һәм Васильев иптәшләрнең берничә станокта эшләүгә күчүләре продукция эшләп чыгаруны арттырырга һәм хезмәт җитештерүчәнлеген ике тапкыр күтәрергә мөмкинлек бирде. Без 1939 нчы елның башында билгеләнгән эшләп чыгару нормаларын уртача 150 процентка үтәүгә ирештек.

Ләкин ирешелгәннәр белән тынычланып калу большевикларга хас нәрсә түгел. Без хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү өлкәсендә планны үтәүдә алга таба барырбыз.

Безнең заводка Сталинчыл өченче бишьеллыкта хезмәт җитештерүчәнлеген, икенче бишьеллыкның соңгы елы — 1937 нче ел белән чагыштырганда 104 процентка күтәрү заданиесе бирелде. 1942 нче елны һәрбер эшченең еллык эшләп чыгарышы 46.800 сумлык булырга тиеш.

Өченче бишьеллыкның беренче ике елы эчендә безнең заводта хезмәт җитештерүчәнлеге 56 процентка үсте. Үзебезнең резервларыбызны һәм практик мөмкинлекләребезне җентекләп исәпләп, **без хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча бишьеллык планны дүрт елда үтәргә өстебезгә йөкләмә алабыз.**

Моның өчен бездә нинди резервлар бар?

Беренчедән — стахановчылык хәрәкәте һәм аның яңа формаларын үстерү: күп станокта эшләү һәм бер үк вакытта берничә профессия буенча эшләү. 1940 нчы елның беренче яртысында без күп станокта эшләүчеләр санын ике өлеш арттырырга сүз бирәбез.

Икенчедән — бракны кискенлек белән киметү, эшчеләрнең эшсез торуларын бетерү һәм эш көненнән тулы файдалану. Без 1940 нчы елны, бракны, 1939 нчы ел белән чагыштырганда, 25 процентка киметергә сүз бирәбез.

Өченчедән—кечкенә механизация һәм станокларны автоматлаштыруны кертү: упорлар, автомат включательләр, станокларның җитештерүчәнлеген күтәрә торган нәрсәләр ясау.

Дүртенчедән—цехларда рационализация үткәрү һәм технология процессларын яхшырту. Нормалаштырылган инструментлар эшләүнең барлык технологик процессларны 1940 нчы елны яңадан карап чыгарга һәм яхшыртырга сүз бирәбез.

Бишенчедән—эшләп чыгаруның искергән нормаларын яңадан карау, аларны алдынгы нормалар белән алмаштыру.

Безнең 1940 нчы ел планы 1939 нчы елгы планнан 25 процентка артык. Без шушы производство планын хәзерге сандагы эшчеләр белән үтәргә йөкләмә алабыз.

Моның өчен без заводның барлык цехларында һәм бригадаларында социалистик ярышны һәм стахановчылык хәрәкәтен тагын да киңрәк җәелдерербез.

Без үзебезнең инициативабызны якларга, **большевикларча эшләү белән өченче бишьеллыкның хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү заданиеләрен дүрт елда үтәүне тәэмин итәргә** чакырып, Ватаныбыздагы машина төзелеше заводларының барлык работникларына мөрәҗәгать итәбез. Бу, Ватаныбызның куәтен арттырыр һәм СССР ның төп экономик бурычын үтәүне тизләтер.

Совет машина төзүчеләрен Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге социалистик ярышны тагын да күберәк энергия белән җәелдерергә, хезмәт җитештерүчәнлеге өлкәсендә әйбернең үзенә төшкән бәясен киметү, ягулыкка, электр энергиясенә һәм производство материалларына экономия ясау өлкәсендә конкрет йөкләмәләр алырга һәм бу йөкләмәләрне большевикларча үтәргә чакырабыз.

Стахановчылык хәрәкәтен тагын да күтәрү өчен! Сталинчыл Өченче Бишьеллык исемендәге ярыш байрагын югарырак! 1940 нчы ел планының сан һәм сыйфат күрсәткечләрен үтәү һәм арттып үтәү өчен, машина төзелешендә хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча бишьеллык планны дүрт елда үтәү өчен!

Социалистик Ватаныбызның яңа, гүзәл җиңүләренә!

Яшәсен юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин!

Мөрәҗәгать Москвадагы инструменталь заводы эшчеләренең, эшче хатын-кызларының, инженер-техник работникларының һәм хезмәткәрләренең тулай завод җыелышында кабул ителде. („Правда", 2 гыйнвар).

ЯРЫШ ДОГОВОРЫН БЕЗ НИЧЕК ҮТИБЕЗ

Колхоз кырлары уңыш бирүне елдан-ел арттыра баралар, социалистик терлекчелек кызу рәвештә үсә. Алга таба булган хәрәкәткә табигать капризлары да, башка сәбәпләр дә комачаулый алмыйлар.

Буа районының Каганович исемендәге колхоз членнары, Сталин заданиесе өчен—ел саен кимендә 8 миллиард пот иген уңышы алу өчен көрәшеп, соңгы елларда зур уңышларга ирештеләр. 1937—1938 нче елларда колхоз һәрбер гектардан уртача 16,62 центнер уңыш алды. Колхоз арыш, солы һәм бодай уңышы күрсәткечләре буенча 1939 нчы елны Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашты һәм беренче дәрәҗәле диплом алды.

1939 нчы ел, һава шартларының бер кадәр начар булуына карамастан, без барлык культуралар буенча гектарыннан уртача 8,22 центнер уңыш алдык. 1 нче октябрьгә барлык ашлыкларны сугуны тәмам иттек. Дәүләткә ашлык тапшыру планын 8 нче сентябрьгә үк үтәдек.

Бу уңышларның барсына да без Татарстан белән Башкыртстан арасындагы социалистик ярыш договорын үтәү өчен большевикларча көрәш җәелдерү аркасында ирештек. Язгы чәчү һәм урып - җыю эшләре вактында колхозчылар барсы да ярыштылар. Шуның нәтиҗәсендә, барлык авыл хуҗалыгы эшләрен һәм дәүләт йөкләмәләрен билгеләнгән срокларда төгәл үтәдек.

Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә алган бай тәҗрибәдән файдаланып, без 1940 нчы елны югары уңыш алу өчен көрәшәбез. Бригадаларда даими звенолар оештырдык һәм алар өчен даими участкылар билгеләдек. Алар бу участкыларда көзге чәчү үткәрделәр инде. Көзге чәчү 17 нче августка төгәлләнде. Тунга сөрү планының 90 проценты 1 нче октябрьгә, калган 10 проценты октябрь аенда үтәлде. Басуга 16 мең йөк тирес чыгарылды. Хәзер орлыкларны чистарту эше бара. Агротехник иптәш Вәлиев һәм тәҗрибәче иптәш Гарипов җитәкчелегендә агроукулар оештырылды.

Колхоз терлекчелек өлкәсендә дә зур уңышларга иреште. 1938 нче елны дәүләт планын яхшы итеп үтәгән өчен колхозның сарык үрчетү фермасы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты һәм икенче дәрәҗәле диплом алды. 1939 нчы елны ферма бәрәннәр үрчетү планын 113 процентка үтәде. Хәзер фермада 700 баш сарык бар. Болардан тыш ферма 260 баш сарыкны башка колхозларга һәм колхозчыларга сатты. Быел колхоз яңадан товарлыклы сөтчелек фермасы оештырды.

Безнең колхоз көннән-көн ныгый. Быел без двигателле яңа тегермән төзедек, электростанция төзүне планлаштырдык.

Ф. Җәмалиева.

Буа районының Каганович исемендәге колхозы председателе, СССР Верховный Советы депутаты.

СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШНЫҢ КӨЧЕ

1939 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы үткәрү өчен Норлат районы Кайбыч районы белән социалистик ярыш договоры төзегәннәр иде. Шушы договор нигезендә Норлат районындагы колхозлар, бригадалар һәм аерым колхозчылар, тракторчылар һәм комбайнчылар үзара социалистик ярыш договорлары төзеп, договор буенча алынган йөкләмәләрне тулысынча үтәү өчен большевистик көрәш җәелдерделәр. Шуның нәтиҗәсендә Норлат районының күпчелек колхозлары зур җиңүләргә ирештеләр. Авыл хуҗалыгы эшләрен үтәү буенча район республика күләмендә алдынгы районнарның берсе булуга иреште. Социалистик ярышның гаять зур көчкә ия булганлыгын аерым колхозлар тәҗрибәсендә ачык күрергә була.

Ленин исемендәге колхоз „Көчле Ирек" колхозы белән ярыша. Ярыш договорларының үтәлеше һәр вакытта тикшереп барыла. Бу колхозлар 1939 нчы елгы авыл хуҗалыгы эшләрен һәм дәүләт йөкләмәләрен үтәүне уңышлы итеп төгәлләделәр. „Көчле Ирек" колхозында кайбер эшләр буенча артта калу булды. Ленин исемендәге колхоз үзе белән ярышучы бу колхозга социалистик булышлык оештырды, үзенең уңышлы тәҗрибәләрен аңа күчерде. Нәтиҗәдә бу колхозның да эше алга китте. Хәзер бу колхозлар язгы чәчүгә яхшы хәзерләнәләр. Ленин исемендәге колхоз машиналарга ремонт ясау һәм орлыкларны чистарту эшләрен төгәлләде инде. Бу эшләр шулай ук „Көчле Ирек" колхозында да уңышлы бара.

Үзара ярышучы „Активист" һәм „Кызыл Урманчы" колхозлары тәҗрибәсендә дә социалистик ярышның уңышлы нәтиҗәләре турында күп кенә мисалләр китерергә була. Бу колхозлар да 1939 нчы елны барлык эшләрне уңышлы рәвештә төгәлләделәр. „Активист" колхозы Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсе Комитеты тарафыннан икенче дәрәҗә диплом, 5 мең сум акча һәм мотоцикл белән бүләкләнде. Бу колхозлар язгы чәчүне үрнәк рәвештә каршылау өчен социалистик ярыш җәелдерделәр.

Шуның белән бергә районда әле социалистик ярышның көченә бәя биреп җиткермәүче колхозлар да бар. Мисаль өчен „Туры юл" колхозын алырга була. Колхозда бригадалар һәм аерым колхозчылар арасында төзелгән социалистик ярыш договорларының үтәлеше бер генә тапкыр да тикшерелмәгән. Бу колхоз белән ярышучы „Игенче" колхозы делегациясе социалистик ярыш договорларын тикшереп, колхозда булган җитешсезлекләрне бетерү һәм үзендәге уңышлы тәҗрибәләрне бу колхозга да күчерү буенча күп кенә эшлекле такдимнәр калдырган. Ләкин колхоз җитәкчеләре (председателе иптәш Хәйруллин) күрсәткән такдимнәрне тормышка ашыру буенча бер нәрсә дә эшләмәгәннәр. Нәтиҗәдә бу колхоз авыл хуҗалыгы эшләрен бик соңга калып тәмамлады. Колхозда язгы чәчүгә хәзерлек эшләре башланмаган да әле. „Кызыл Партизан" колхозында да шундый ук хәл.

Колхозлар, бригадалар арасында бара торган социалистик ярышка район оешмалары тарафыннан җитәкчелекнең тиешенчә булмавын әйтергә кирәк. Шулай ук районнарара төзелгән ярыш договоры буенча 1939 нчы елгы эшләргә карата йомгак ясалмаган әле. Район оешмалары җитәкчеләре социалистик ярышка якыннан торып җитәкчелек итәргә тиешләр.

Х. Хәлилов.

БЕЗНЕҢ ЙӨКЛӘМӘБЕЗ

Совет агрономнарына партиябез һәм хөкүмәтебез тарафыннан гаять зур бурычлар йөкләтелгән. Агрономнар колхозларда һәм совхозларда техник җитәкчеләр, оештыручылар сыйфатында югары иген уңышы яулап алуда партия һәм совет оешмаларына, колхоз җитәкчеләренә, колхозчыларга якыннан булышлык итәргә, агрономиянең яңа алымнарын куллануны оештырырга тиешләр.

Һәрбер агроном моны бер минутка да онытмаска һәм үзенең бөтен эшен шуннан чыгып оештырырга тиеш.

Без, Сарман районы агрономнары, илебездә көннән-көн киңрәк урын ала бара торган йөз потчылар хәрәкәтенә кушылып 1940 нчы елда һава шартларының нинди булуына карамастан бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 100 пот уңыш алу бурычын куябыз. Моңа ирешү, агротехника чараларын төгәл һәм дөрес үткәргәндә генә, югары уңыш өчен көрәшкә барлык колхозчыларны оста итеп туплый белгәндә генә мөмкин.

Без быел чәчү орлыкларын чистартуны иң кыска срокта яхшы сыйфатлы итеп төгәлләүне, җирле ашламалардан киң файдалануны, басуга 91 мең тонна тирес, 10.000 тонна торф чыгаруны, колхозларда 700 тонна көл, 560 тонна фекаль, 250 тонна кош тизәге, 600 тонна тирес сыекчасы җыюны, 1.800 тонна компост хәзерләүне һәм 20 мең гектарда кар тотуны тәэмин итәргә йөкләмә алабыз.

Агрономияне киң куллану, бигрәк тә аның яңа алымнарын масса төсендә үткәрү өчен колхозчыларны агротехника белеме белән коралландыру таләп ителә. Без 4.500 колхозчыны агротехника түгәрәкләрендә укытып чыгарырга, ике колхозда агрономнарның турыдан-туры җитәкчелегендә колхоз җитәкчеләре, бригадирлар, звено башлыкларын укыту өчен ефримовчылар түгәрәге оештырырга сүз бирәбез. Районның һәрбер колхозында колхозчылардан агротехниклар хәзерлибез. Кимендә 32 колхозда хата-лаборатория, 32 колхозда тәҗрибә участкылары оештырабыз.

Даими звеноларны барлык колхозларда да хәзердән үк оештырабыз. 32 колхозда ефримовчы звенолар төзелә.

Язгы чәчүне кыска срокта югары сыйфатлы итеп үткәрү, югары уңыш алуда хәл иткеч шартларның берсе. Ә чәчүне уңышлы үткәрү өчен аңа бик яхшы итеп хәзерләнергә кирәк. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьларына югары сыйфатлы ремонт ясау, транспорт инвентарьларын җитәрлек хәзерләү өчен без барлык чараларны күрәбез. Бу эштә колхоз җитәкчеләренә практик булышлык күрсәтәбез.

Без алган йөкләмәләребезнең зур һәм гаять җаваплы булуын яхшы аңлыйбыз. Бу йөкләмәләрне үтәү өчен безгә, агрономнарга совет, партия оешмалары, колхоз җитәкчеләре белән кулга кул тотынып эшләргә, колхозчылар арасында аңлату эшләрен өзлексез алып барырга кирәк. Без моны эшләрбез һәм йөкләмәләребезнең тулы үтәлүенә ирешербез.

Агрономнар: Мутин, Тимергалин, Раимов, Хәбибуллин, Шәрипов, Арсланов, Салахов, Нафиков, Саитгәрәев, Мортазин, Хәмитова, Заитов, Әхметшин.

Казан тимер юлының үсеш перспективалары

Г. Е. БУСЫГИН

Казан тимер юлының план бүлеге начальнигы

Социалистик тимер юл транспорты җиңүле рәвештә алга бара. Икенче бишьеллык планны ул 4 елда үтәде. Тимер юл транспорты хәзер халык хуҗалыгының алдынгы бер тармагы булып әверелде.

Сталинчыл өченче бишьеллыкта тимер юл транспорты тагын да кызуырак үсү мөмкинлеген алды. Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды тимер юлда капиталь эшләр күләмен өченче бишьеллыкта 37,3 миллиард сумлык итеп билгеләде. Үсеш икенче бишьеллык белән чагыштырганда 80 процент дигән сүз. Йөк әйләнешен 1937 нче елгы 355 миллиард тонна-километрдан 1942 нче елда 510 миллиард тонна-километрга кадәр үстерү билгеләнде. Хезмәт җитештерүчәнлеге тимер юл транспортында 32 процентка күтәрелергә, йөк төяү-бушату эшләре тулысы белән механикалаштырылырга тиеш. Локомотивлар һәм шулай ук вагоннар паркы да арттырыла һәм күп кенә көчәйтелә.

Югарыда күрсәтелеп үткән саннар тимер юл транспортының үсеш юлларын тулы гәүдәләндерәләр. Моны без Казан тимер юлы мисалендә дә ачык күрә алабыз.

Казан тимер юлы—ул илебезнең тимер юл магистралендә гаять зур һәм әһәмиятле тармакларның берсе. Безнең юл хезмәт күрсәтә торган территория 232 мең квадрат километр күләмендә исәпләнә һәм Татарстан, Чувашстан, Удмуртия, Мари, Мордва, Башкыртстан республикалары һәм Москва, Иваново, Горький, Пермь, Свердловский, Киров өлкәләре аша үтә. Безнең тимер юл Ленин исемендәге юл белән, Пенза, Горький һәм Л. М. Каганович исемендәге тимер юллар магистральләре белән, Волга, Ока һәм Кама елгалары белән тоташа. Югарыда күрсәтелгән республикаларның һәм өлкәләрнең халык хуҗалыгы үсешендә Казан тимер юлы хәл иткеч урын тота.

Сталинчыл икенче бишьеллыклар чорында Казан тимер юлында йөк әйләнеше ике тапкыр үсте. Ә өченче бишьеллыкта ул тагын да 80 процент үсеш бирергә тиеш. Бу бурычларны уңышлы рәвештә тормышка ашыру өчен Казан тимер юлы тагын да катлаулырак һәм көчлерәк техника белән баетыла, яңа юллар төзелә.

Монда Казан—Бөгелмә тимер юлын төзү, Ока елгасы аша зур күпер салу, хәзерге вакытта төзелеп беткән Канаш—Чебоксар тимер юлын эксплуатациягә бирү кебек гигант эшләрне аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Бу төзелешләрнең әһәмияте Казан тимер юлы өчен генә түгел, бәлки гомумән бөтен илебез өчен дә гаять зур. Бу гигант төзелешләр бөек социалистик Ватаныбызның халык хуҗалыгын тагын да кызу темплар белән үстерүгә хезмәт итәчәк. Алар безнең Казан тимер юлы белән бәйләнгән республикаларның һәм өлкәләрнең йөзен тамрыннан үзгәртәчәк. Казан—Бөгелмә тимер юлын эксплуатациягә бирү үзе генә дә Казан тимер юлының йөк әйләнешен 2 миллион 500 мең тоннага арттырачак.

Өченче бишьеллыкта паровозларның тарту көчләрен арттыру буенча да зур эш үткәрелә. Монда хәзерге көндәге гади паровозларны яңа, көчле паровозлар белән алмаштыру эше үткәреләчәк. Казан тимер юлының аеруча әһәмиятле тармакларында „ФД" паровозлары кулланылачак. Бу хәл исә товар поездларының йөк авырлыгын 25 процентка үстерү белән бергә, поездларның йөреш тизлелеген дә күп кенә арттырачак. „ФД" паровозлары 10 мең тонна йөк төялгән составны бер юлы алып бара алалар. Мондый составларның озынлыгы 2 километрга җитә.

Билгеле, паровозлар паркын болай көчлеләндерү юлларны реконструкцияләү мәсьәләсен дә катылык белән куя. Өченче бишьеллыкта 1000 километр юлга реконструкция үткәреләчәк. Хәзерге рельсләр һәм шпаллар ныграк, чыдамлырак рельсләр һәм шпаллар белән алмаштырылачак. 1938 нче һәм 1939 нчы елларда бу планның 25 проценты үтәлде дә инде. Бу юлларда хәзер „ФД" паровозлары үзләренең гүзәл эшләрен башкаралар.

Шул ук вакытта паровоз деполарын тәртипкә китерү, аларны механикалаштыру һәм күләмнәрен зурайту өлкәсендә дә зур гына эшләр башкарыла.

Хәзерге деполар „ФД" паровозларын ремонтлый алырлык итеп яңа баштан корылалар. Яңа деполар төзегәндә, ә искеләрен реконструкцияләгәндә депо эшчеләренең хезмәт шартларын яхшыртуга зур игтибар бирелә. Һәрбер депода кызыл почмак, техника кабинеты, душ, медицина пункты һәм башкалар булдырылачак. Паровозларны ягулык һәм майлау материаллары белән тәэмин итү, ягылган күмер шлагын алу кебек эш процесслары механикалаштырылачак. Бу чараларны тормышка ашыру, хезмәт шартларын күп яхшыртачак, хезмәт җитештерүчәнлеген югары күтәрәчәк, паровозларны эксплуатацияләү буенча булган расходларны хәзергегә караганда 50 процент киметәчәк.

Юдино станциясендәге сортировка горкасының үсеше турында аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк. Монда хәзерге көндә кул көче белән башкарыла торган эш — поездларны формировать итү тулысы белән механикалаштырыла.

Поездларның йөк ташуларын һәм тизлелекләрен арттыру поездлар хәрәкәтенең куркынычсызлыгы турындагы мәсьәлә белән аеруча шөгыльләнүне таләп итә. Өченче бишьеллык планында бу мәсьәлә үзәк урыннарның берсен алып тора. Хәзер бу өлкәдә Казан тимер юлының эре участкыларында практик эшләр башкарыла. Стрелкалар электр көче белән үзәкләштереләләр. Бу исә күп санда эш көчләрен азат итәчәк һәм юлыбызның эре станцияләрендә поездларны формировать итү эшен тизләтәчәк. Диспетчерскийларны үзәкләштерү, ягни поездлар хәрәкәтен автомат көче белән күзәтү, аларның хәрәкәтенә дөрес юнәлеш биреп тору поездлар хәрәкәтенең куркынычсызлыгын тәэмин итүдә зур чара булып тора.

Казан тимер юлын техник яктан коралландыру, паровоз һәм юллар хуҗалыгын яңарту, поездлар хәрәкәтен тагын да яхшырак итеп оештыру буенча — Сталинчыл өченче бишьеллыкта билгеләнгән кайбер чаралар әнә шундый. Ләкин бөек эшләр планы моның белән генә чикләнми әле.

Вокзаллар һәм культура-агарту учреждениеләре, шулай ук торак йортлар төзү, пассажирларга культуралы хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә гаять әһәмиятле эшләр үткәрелә. Мәсәлән, пассажир поездларын моннан соң көчле „ИС" паровозлары йөртәчәкләр. Алар үзләренең югары эш күрсәткечләре белән Казан белән Москва һәм Казан белән Свердловский арасындагы юлны хәзергегә караганда ике-өч сәгатькә кыскартачаклар. Канаш һәм Арзамас станцияләрендә яңа вокзаллар салына. Күп кенә вокзаллар киңәйтеләләр. Бу вокзалларда ял итү, юыну-душ бүлмәләре, ана һәм балалар бүлмәсе оештырыла. Бу вокзалларның зурлыгын күз алдына китерү өчен түбәндәге мисаль дә җитә: Канаш станциясе вокзалының күләме хәзерге Казан вокзалына караганда ике тапкыр зуррак булачак. Тимер юлчылар өчен дистәләрчә зур-зур торак йортлар, больницалар, мәктәпләр һәм клублар төзелә.

Партиябезнең тарихи XVIII нче съезды карарлары белән рухланган тимер юлчылар коллективы алда торган бу гаять әһәмиятле бурычларны бердәм рәвештә үтәү хисе белән сугарылган. Сталинчыл өченче бишьеллыкта Казан тимер юлының үсеш перспективалары гаять зур һәм без бу бурычларны, һич шиксез, большевикларча үтәрбез. Казан тимер юлын бөек социалистик Ватаныбызның тимер юл челтәрендә иң алдынгы бер тармак итәрбез.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

ЛОНДОН, 1 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәренә караганда, үткән атна эчендә, дошманның хәрәкәтләре нәтиҗәсендә, Англиянең 3 пароходы һәм нейтраль илләрнең 2 пароходы батырылган.

Агентлыкның хәбәр итүенчә, Германиянең Англия сугыш карабы тарафыннан тотып алынган „Глюксбург“ исемле сәүдә пароходы Чипионда (Испания) ярга бәреп чыгарылган.

1 нче гыйнварда Төньяк диңгездә, шартлау нәтиҗәсендә, Англиянең 5.677 тонна авырлыктагы „Вокс хилл“ пароходы баткан. 32 кешелек командадан 12 кеше коткарылган. Калган 20 кешене һәлак булган дип уйлыйлар.

Төньяк Шотландия ярлары буенда су асты көймәсе Англиянең „Барбара Робертсон“ тралерын батырган. Аның командасы Англиянең сугыш карабына алынган.

ОСЛО, 2 гыйнвар. (ТАСС). Норвегия телеграф агентлыгының хәбәр итүенә караганда, кичә иртә белән Төньяк диңгездә Норвегиянең „Люна“ исемле йөк пароходы минага бәрелеп баткан. Экипажы коткарылган.

НЬЮ-ЙОРК, 2 гыйнвар. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының хәбәренә караганда, Уругвай властьлары Германиянең „Такома“ пароходын тотып алганнар.

БЕРЛИН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Германиянең Монтевидеодагы илчесе „Такома“ пароходын тоткарлауга каршы Уругвай хөкүмәтенә протест белдергән.

ПАРИЖ, 2 гыйнвар. (ТАСС). Гавас агентлыгы болай дип хәбәр итә: „1940 нчы елның беренче көне фронтта тыныч үтте. Тик патрульләрнең һәм күзәтче отрядларның гадәттәге хәрәкәтләре генә булды. Фронт өстендә авиация дә чикләнгән хәрәкәтләр генә ясады“.

БЕРЛИН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе үзенең сводкасында түбәндәгеләрне белдерә: „Көнбатышта артиллериядән сирәк кенә атышулар булды. 31 нче декабрьдә, Англия самолетлары Төньяк диңгезнең Германия ярыннан күзәтүдән кайтканда Голландия территориясе өстеннән очып үттеләр. 1 нче гыйнварда Германиянең һава көчләре Шетланд һәм Оркней атаулары өстендә бернечә күзәтү очышлары үткәрделәр һәм шул вакытта күп кенә кыйммәтле мәглүматлар таптылар. Безнең күзәтчеләребезнең бер өлеше Шотландия ярыннан 200 километр ераклыкта дошманның зур көчләре белән очрашты. Германиянең бер самолеты суга төшәргә мәҗбүр булды. Англиянең бер самолеты шул кадәр нык зарарланды, аның үз базасына кайтуы икеле“.

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең авиация министрлеге очучылар составындагы югалтуларның чираттагы исемлеген игълан итте. Үтерелгәннәрне, ярадан үлгәннәрне һәм моннан элек хәбәрсез югалган дип саналган кешеләрне кертеп исәпләгәндә соңгы вакытта барлыгы 48 кеше һәлак булган.

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Англиянең авиация министрлеге, Төньяк диңгез районында патруль хезмәте алып баручы, яр буе оборонасы самолетларының кичә Германиянең бер самолетын бәреп төшергәнлекләрен игълан иткән. Министрлекнең белдерүендә болай диелә: „Кичә Шотландиянең көнчыгыш ярыннан 130 миль ераклыкта диңгез өстендә булган һава сугышы вактында Англиянең 3 самолеты Германиянең Гейнкель системасындагы ике моторлы 2 самолеты белән сугышканнар. Сугыш ярты сәгать дәвам иткән. Англия самолетларыннан берсе Германия самолетына шактый зур зыян китергән.

Германиянең икенче самолеты Англиянең 2 самолеты тарафыннан атакага очраган, ләкин ул болытлар арасына яшренеп, котылып китә алган“.

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгы корольнең приказ чыгарганлыгын хәбәр итә. Бу приказ буенча мәҗбүри гаскәри хезмәт турындагы закон 19 дан 28 яшькә кадәр булган барлык ирләргә кагыла.

Рейтер агентлыгы бу чараның армия санын 2 миллион кешегә арттырачагын хәбәр итә. Октябрь аенда теркәлгән 230 мең кеше белән һәм 1939 нчы елның декабрендә теркәлгән 240 мең кеше белән берлектә, армиягә чакырылганнарның гомуми саны 2 миллион 750 мең кешегә җитәчәк.

ЛОНДОН, 3 гыйнвар. (ТАСС). Авиация министрлеге, кичә көндез Төньяк диңгез өстендә Германия ярлары якынында Англиянең бомбардировщиклары Германиянең ерак радиуска хәрәкәт итә торган „Мессершмитт“ дигән 12 истребителе белән очрашканнар, дип хәбәр итә. Бер „Мессершмитт“ бәреп төшерелгән, Германия истребительләренең 2 се суга төшәргә мәҗбүр булганнар һәм, һәлак булган булсалар кирәк. Сугыш вактында Англиянең бер бомбардировщигы бәреп төшерелгән, 2 се хәбәрсез югалган.

БЕРЛИН, 3 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы, Англиянең „Виккерс-Веллингтон“ дигән яңа конструкциядәге өч хәрби самолеты кичә көннең икенче яртысында Германия бухтасына һөҗүм итәргә маташкан, дип хәбәр итә. Самолетлар Германиянең „Мессершмитт“ истребительләре эскадрельясе тарафыннан каршы алынган. Кыска гына сугыш нәтиҗәсендә Англиянең барлык 3 самолеты да бәреп төшерелгән. Германия авиациясе бер самолет та югалтмаган.

ПАРИЖ, 3 гыйнвар. (ТАСС). Фронтта авиациянең хәрәкәте бер кадәр яңадан башланды, дип рәсми рәвештә хәбәр ителә. Кичә һәм бүген төнлә белән фронтта артык бер нәрсә дә булмаган.

ВЕРЛИН, 3 гыйнвар. (ТАСС). Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәге сводканы тапшыра:

„Көнбатыш фронтта артиллериянең һәм разведка частьләренең артык зур булмаган хәрәкәтләре, шулай ук авиациянең патруль һәм күзәтү очышлары булды“.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Кантоннан төньяк—көнчыгышта Лянкоу секторында каты сугышлар башланып китте. Японнар үзләренең Кантоннан төньяктарак Индэне алганлыкларын раслыйлар. Бу районда японнарның 3 дивизиясе хәрәкәт итә.

Японнарның 6 мең кешелек бер отряды Кантоннан төньяк-көнбатышта Готай районында кытайларның позицияләренә атака ясады. Кытайларның оборонасы каршы һөҗүмгә күчеп, дошманга зур югалтулар китерде.

„Дамэйбао“ газетасының язуына караганда, кытай гаскәрләренең һәм партизаннарның һәр вакыт атака ясап торулары нәтиҗәсендә 30 нчы декабрьдә япон частьләре Кантон—Коулун тимер юлындагы Шэньчуньны һәм Шатолкоуны ташлап киткәннәр. Икенче көнне бу пунктларны кытай гаскәрләре алган.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең төньяк өлешендә кытай гаскәрләре Датун—Пучжоу тимер юлында, Нин—Удан көньяк-көнчыгышта Чжанчэнь станциясен алганнар һәм бу пункт белән Юаньпин арасындагы тимер юлны җимергәннәр.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Үзәк Кытай фронтындагы хәлләр турында хәбәрләр юк.

31 нче декабрьдә Гуанси провинциясендәге Лючжоу өстендә япон һәм кытай истребительләре арасында зур һава сугышы булган. Японнарның 18 самолетларыннан 8 е бәреп төшерелгән.

ЛОНДОНДЕРРИДӘ БОМБА ШАРТЛАУ

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Лондондерри (Эйре) шәһәрен караңгыландырган вакытта Үзәк пожарный часть бинасына бомба ташланган. Шартлаудан бер пожар машинасы һәм бер түбә җимерелгән. Кешеләргә зыян килмәгән. Бомбаны „Ирландия республика армиясе“ нең кулга алынган членнары арасында рождество бәйрәме вактында Лондондерри төрмәсендә булган чуалышларны бастыруда пожарникларның катнашканлыгы өчен җәза чарасы сыйфатында ташлаганнардыр дип уйлыйлар.

АНГЛИЯ КАБИНЕТЫ СОСТАВЫНДА БУЛАЧАК ҮЗГӘРЕШЛӘР

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). „Ньюсь кроникл“ газетасының политик күзәтчесенең язуына караганда, мәсьәлә белән яхшы таныш булган хөкүмәт даирәләрендә, якын араларда Англия кабинеты составында үзгәрешләр булуны көтәләр. Макмиллан информация министрлеге постыннан азат ителер дип уйлыйлар. Бу постка Уолтер Монктон куелуы ихтимал диләр.

Лаеш районы балалар уку йорты 1.128 укучыга хезмәт күрсәтә. РӘСЕМДӘ: уку йорты мөдире иптәш А. А. Евдокимова укучыларга китап бирә.

С. Чиколкин фотосы (ТатТАСС фото-хроникасы).

ТАТАРСТАНДА КИНО-ТЕАТРЛАР ЧЕЛТӘРЕ

Кинофикациянең Татарстан Тресты кино челтәрен тагын да җәелдерү буенча һәм, аеруча район үзәкләрендә тавышлы кино-театрлар ачу буенча шактый уңышларга ирешә. Татарстан тресты бу өлкәдә союзда алдынгы трестларның берсе булып санала.

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек чорында кинофикация тресты алдына гаят зур бурыч куелды. Трест 24 нче декабрьгә—сайлаулар көненә 21 район үзәгендә кино-театрлар ачарга тиеш иде. Киноаппаратларын һәм оборудованиеләрне районнарга алып бару өчен көзге-кышкы шартларның бик авыр булуына да карамастан, урыннарда партия оешмаларының һәм совет органнарының ярдәме белән бу эш тулысынча һәм уңышлы рәвештә үтәлде. Шулай итеп орденлы Татарстан республикасының район үзәкләре сайлаулар көнен тулы кинофикацияләштерелгән хәлдә каршы алдылар.

Бөек большевиклар партиясенең тарихи XVIII нче съезды Сталинчыл өченче бишьеллык планда тавышлы киноустановкаларны 5—6 тапкыр арттыру бурычын куйды. Безнең республикабызда съезд тарафыннан куелган бу бурыч уңышлы хәл ителә.

Республикабызның барлык район үзәкләрендә тавышлы кинотеатрлар ачу белән бергә, 63 урында автомобильдә тавышлы кино оештырылды, 46 колхозда стационар тавышлы киноларның тар пленкалы аппаратлары куелды. Болар колхозларда, совхозларда һәм МТС ларда хезмәт ияләренең киң массасына хезмәт күрсәтәләр. Болардан тыш, республикада 140 тавышсыз кинопередвижкалар эшли.

Кино челтәренең зур адым белән үсүе Кинотрест һәм Союзкинопрокат җитәкчеләре алдына тагын да зуррак бурычлар куя. Һәрбер урында кино-механикларның тулы квалификацияле кадрларын булдыру, аларны тәрбияләп үстерү, кино-театрларны картиналар белән үз вактында тәэмин итү, электростанцияләрне ягулык белән тәэмин итү,—алар барсы да кино-театрларның нормаль эшләүләре өчен төп шарт булып торалар.

Ләкин бу җаваплы эшне уңышлы башкару өчен кинотрест работникларына зур булышлык кирәк. Урындагы партия һәм җәмәгать оешмалары бу өлкәдә кинотрестка ярдәмгә килергә тиешләр.

Әхмәтов. Краев.

КАРТ УКЫТУЧЫ

Карт укытучы Г. Таһиров иптәшнең халык мәгарифе өлкәсендә эшли башлавына 30 ел тулды. Татарстан Наркомпросы, Казан шәһәр һәм район мәгариф бүлеге, 18 нче номерлы урта мәктәпнең укытучылар коллективы 5 нче гыйнварда аның юбилеен үткәрәчәкләр.

Иптәш Таһиров 1894 нче елда, хәзерге Куйбышев өлкәсендә туган. 1910 нчы елда Казандагы „Касимия“ мәдрәсәсен тәмамлаган һәм 16 яшеннән укытучы булып киткән. Бөек Октябрьгә кадәр гаят авыр шартларда укыткан, ләкин ул шулай да укытучылык эшен ташламаган.

Иптәш Таһиров яхшы укытучы һәм тәҗрибәле методист. Карт укытучылар да, яшь укытучылар да аның тәҗрибәләрен уртаклашалар, аңардан методик киңәшләр алалар. Ул җәмагать эшләренә дә актив катнаша. Ул 18 нче номерлы мәктәптә тел-әдәбият фәннәре буенча укытучы һәм уку-укыту эшләре мөдире булып эшли.

Хәзерге көндә аның бик күп укучылары ВУЗ тәмамладылар. Аларның күбесе үзләре дә укытучы булып эшлиләр һәм үзләрен укыткан иптәш Таһировны онытмыйлар. Аннан методик киңәшләр алалар һәм үзләренең тәҗрибәләрен уртаклашалар.

Ларюкова.

18 нче мәктәп укытучысы.

КОЛХОЗДА ТАВЫШЛЫ КИНО

1939 нчы елның 1 нче октябрендә Кәче авылындагы „Авангард“ колхозында (Арча районы) тавышлы кино эшли башлады. Тавышлы кино колхозның үз гидро электростанциясе ярдәме белән эшләтелә. Тавышлы кинода эшләү өчен колхоз үзенең кадрларын хәзерләде. Колхозчы Абдулла иптәш Камалиев кино-механик булып эшли.

Колхозчылар ай саен 4 тапкыр мәктәп бинасында кино карыйлар. Кино-картиналарның һәр берсе көндез балаларга, кичләрен зурларга күрсәтелә. 3 ай вакыт эчендә 11 төрле кино-картина күрсәтелде. Колхозчылар картиналарны яратып карыйлар. Һәр сеанста 200—220 кеше була. Моңа кадәр күрсәтелгән картиналар арасында „Ленин Октябрьдә“, „Чапаев“, „Унеч“ һәм башка фильмнәр бар иде.

Тавышлы кино эшли башлаган көннән алып хәзергә кадәр куелган картиналарны карарга 18 меңгә якын кеше килде.

Нур Хәйруллин.

БИК КҮП КАР ЯВЫМЫ

ЮТАЗЫ, 2 гыйнвар. (ТатТАСС). 1939 нчы елның декабрь аенда Ютазы районында бик күп кар яуды. Җиргә төшкән карның калынлыгы 60—70 сантиметрга җитә. Картларның әйтүенә караганда декабрь аенда мондый күп кар явымы бик күп еллардан бирле булмаган.

Яңа ферма оештырылды

Норлат районы „Көчле Ирек“ колхозында сыер асраучылык фермасы бар иде. Хәзер тагын ике яңа ферма—сарык һәм дуңгыз асраучылык фермалары оештырылды. Ферма кышка яхшы хәзерлек белән керде. Терлекләр җылы һәм чиста урында торалар. Ферма кыш өчен кирәк булган азык-фураж белән тулысынча тәмин ителде.

Яңа фермада хәзер 76 баш сарык һәм 19 баш дуңгыз бар.

Г. Сираҗиев.

ХӘРБИ САНИТАРИЯ ДРУЖИНАЛАРЫ

Казанда 7 предприятиедә хәрби-санитария дружиналары төзелде. Һәрбер дружинаның тулысынча санитария әйберләре—противогазлар, насилкалар, санитария сумкалары бар.

Дружина членнары производстводан аерылмыйча ун ай буенча махсус хәзерлек үтәләр. Алар химия һөҗүменнән саклану чаралары, агуланган һәм яраланган вакытларда беренче ярдәм күрсәтү, яраланучыларны йөртү кагыйдәләрен өйрәнәләр. 2 нче гыйнварда Вахитов исемендәге жиркомбинатта санитария дружинасы курсын бетерүчеләргә беренче чыгарыш булды.

Гыйнвар аенда РОКК ның өлкә комитеты Казанда зур предприятиеләрдә тагы 6 хәрби-санитария дружиналары оештыра. Татарстан районнарында 7 дружина оештырылды. (ТатТАСС).

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

— Бондюг районының Сталин исемендәге колхозында 5 нче гыйнварда 8 койкалык бала тудыру йорты ачылачак.

Бондюгта шулай ук 415 мең сумга төшерелеп урта мәктәп төзелеп бетте. Кышкы каникуллардан соң укучылар яңа мәктәптә укый башлыйлар.

— Красный Бор районы колхозларында 1939 нчы елда 16 МТФ, 25 ОТФ һәм өч СТФ оештырылды. Хәзер, яңа фермалар оештырылганнан соң, районлагы 52 колхозда 103 ферма булды.

— Апас районы Энгельс исемендәге колхозда 13 колхозчы хатынкыз производстводан аерылмыйча трактор эшенә өйрәнәләр. (ТатТАСС).

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Англия тред-юнионнары конгрессы лидерларының „Дейли уоркер“ га каршы походы

ЛОНДОН, 2 гыйнвар. (ТАСС). Англия тред-юнионнары конгрессының лидерлары компартия органы „Дейли уоркер“ газетасына каршы ачыктан-ачык поход башладылар. „Дейли уоркер“—сугыш уты кабызучыларның һәм аларның тред-юнионнар җитәкчеләре һәм лейбористлар партиясе башкарма комитеты җитәкчеләре арасындагы дуслaрының чын максадларын фаш итә торган бердәнбер газета. Конгрессның 7 члены—Ситрин, Джон Броун, Бэгнал, Конли, Хикс, Кэйлор һәм Флоренс Ханкок ханым „Дейли уоркер“ газетасы редакциясен, „яла ягу белән шөгылләнә“ дигән булып судка бирделәр. Суд бу „эш“ не 4 нче гыйнварда караячак.

Төркиядә давыл һәм көчле яңгырлар

ӘНКАРӘ, 2 гыйнвар. (ТАСС). Анатоли агентлыгының хәбәр итүенә караганда, соңгы көннәрдә Көнбатыш Анатолида, бигрәк тә Бруса, Менемен, Измит һәм Маниса районнарында гаят көчле яңгыр белән давыллар дәвам итә. Анатолиның бу өлешендәге уйсулыклар тоташ күлләр булып әверелде. Бик күп авылларны су басты. Күп йортлар җимерелде һәм су ташуы белән агып китте. Бернечә кешене яшен сугып үтерде. Хөкүмәт зарарланучыларга ярдәм оештыра.

АМЕРИКА АРМИЯСЕНӘ ЯШЬЛӘРНЕ ЧАКЫРУ

НЬЮ-ЙОРК, 3 гыйнвар. (ТАСС). „Нью-Йорк уорлд телеграмм“ газетасының хәбәр итүенә караганда, узган елның декабрендә Америка армиясенә яшьләрдән 227 мең кеше алу планлаштырылган булса да, аның бик күп өлеше үтәлмәгән. Шушы уңай белән Америка армиясенең командованиесе армиягә кирәргә чакырып эшсез яшьләргә мөрәҗәгать иткән.

Татнаркомздрав Дәүләт Санитария инспекциясенең

САНИТАРИЯ-ГИГИЕНА ЛАБОРАТОРИЯСЕ

һаваны, туфракны, суларны, чишмә суларын, азык продуктларын, ашларны һәм башкаларны санитария-химик һәм бактериологик анализлау эшләре үткәрү буенча 1940 нчы ел өчен

ДОГОВОРЛАР ТӨЗИ

Лаборатория санитария консультацияләре бирә, шулай ук коммуналь һәм промышленность төзелеше проектлары буенча һәм санитария-гигиена мәсьәләре буенча заключениеләр бирә. Казан, Бутлеров урамы, 16. Телефоннар: 10—39 һәм 43—86.
2661—2—1

Жицел Промышленность Халык Комиссариаты системасындагы
ТЕГҮ ФАБРИКАЛАРЫ

ФЗУ МӘКТӘБЕ

мәктәпнең рус группаларына

УКУЧЫЛАР АЛА

Мәктәпкә 16 дан түбән булмаган яшьтәге кешеләр 7 еллык мәктәп күләмендәге белем белән алыналар. Керүчеләр рус теленнән һәм математикадан сынаулар үтәләр.

Гариза белән бергә, керүченең автобиографиясе, белеме һәм яше турында документлар бирелергә тиеш. Сынаулар 1940 нчы ел, 25 нче гыйнвардан һәм укулар 1 нче февральдән башлана.

Укучыларга, аларның теориядән һәм практикадан өлгерешләренә карап, айга 70 сумнан 140 сумга кадәр стипендия бирелә.

Стипендиядән тыш квартира акчасы да бирелә.

Казан, Дзержинский урамы, 11, тегү фабрикалары ФЗУ мәктәбе. 2643—1

Казмехкомбинат предприятиеләренә Бакалтайдан һәм Аракчино затоныннан күмер ташу өчен, Бакалтайдан агач материаллары, палаткалар шәһәрчеге атавыннан (элекке Маркиз) утын, Аргы Устьедән ком, таш һәм башка материаллар ташу өчен ашыгыч рәвештә

АВТО ҺӘМ АТЛЫ ТРАНСПОРТ КИРӘК

Колхозлар белән договорлар төзергә мөмкин. Казан, Кече Ямашев урамы, 86. Телефоннар: 1—93 һәм 14—83.
2678—1

ВАХИТОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ЖИРКОМБИНАТНЫҢ

ФЗУ МӘКТӘБЕ

мәктәпнең хәзерлек группасына (руслар группасы)

УКУЧЫЛАР АЛА

Хәзерлек группасына 7 класс күләменнән түбән белемле һәм 16 дан түбән булмаган яшьтәге үсмерләр алыналар.

Гариза белән бергә, керүченең яше турында документ, мәктәптән, ата-анасының эшләгән урыннарыннан бирелгән һәм чәчәк салынган булу турында белешмәләр бирелергә тиеш.

Укулар 1940 нчы ел, 15 нче гыйнвардан башлана.

Тулай торак булмый. Вак-төяк расходлар өчен кечкенә стипендия бирелә. Казан, Тукай урамы, 113. Жиркомбинат техникумы бинасы (3 нче маршрут трамваеның Вахитов исемендәге завод янындагы туктавы). 2680—3—1

Казан тимер юлының Бөтенсоюз конторасына, Казанда эшләү өчен ашыгыч рәвештә

өлкән машинистка, эшбашкаручы-ротатор

һәм урыннарга китеп аерым баланс буенча эшләү өчен

өлкән бухгалтерлар

КИРӘК

Казан, Париж Коммунасы урамы, 16.
2585—2—2

1939 нчы ел 16 нчы декабрьдә 13 яшьлек ир бала югалды. Баланың исеме Миңлегаяз һәм фамилиясе Хәернасов. Ул турыда белүчеләннең түбәндәге адрес буенча белдерүләре сорала: Татарстан АССР, Кукмара районы, Купка авылы, Хәернас Закиров. 2—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 4 нче гыйнварда

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Бүген талон 68.

5 нче һәм 6 нчы гыйнварда көндез һәм кич

ПАВЕЛ ГРЕКОВ

Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

КАНИКУЛ КӨННӘРЕНДӘ

6 нчы һәм 12 нче гыйнварда көндезге спектакльләргә коллектив заявкалар буенча килүчеләргә (100 билеттан ким булмаганда) 50 процент ташлама ясала.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Тулысынча яңа программа

Москва 4 нче труппасының гастрольләре.

ЯҢА ЕЛ КАРНАВАЛЫ

Бөтен труппа катнаша.
Орденлы АЛЛИ-ВАД ның һәм ВЕРА МИРОВАНЫҢ соңгы гастрольләре.

12 нче гыйнварга кадәр һәр көн 11 сәгаттә, 2 сәгать 30 минутта һәм кич 8 дә

ЦИРК УЕННАРЫ

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Киров районындагы

Культура сарае

5 нче гыйнварда

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Талон 39.

Спектакль кич сәгать 8 дә башлана.

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

4, 5 нче гыйнварда һәм 6 нчы гыйнварда кич, шулай ук 7 һәм 8 нче гыйнварда премьера

КЫЮ КЫЗЛАР

Бүген талон 87.

6 нчы гыйнварда көндез

КҮЗЛӘР

Талон 89.

Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЕЛЕКТРО“ 10, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез 10 сәгаттә ХӘЗИНӘЛӘР АТАВЫ һәм башка сеансларда ПАРТБИЛЕТ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ДУСЛАР ЯҢАДАН ОЧРАШАЛАР Көндез 10 сәгаттә балалар өчен сеанс
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 11, 1, 3, 5, 7-30 һәм 10 да	Көндезге сеансларда АЛТЫН АЧКЫЧ Кич БӨЕК ГРАЖДАНИН (икенче сериясе)
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	ЦИРК
„ПИОНЕР“ 6, 8 һәм 10 да	Көндез һәм кич ҺАВА ПОЧТАСЫ Көндез 1 сәгаттә мәктәпкәчә тәрбия яшендәге балалар өчен сеанс ВАРЯ КАПИТАН
„РОТ-ФРОНТ“ 10, 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	СОРОЧИНСКАЯ ЯРМАРКА
„КОЛХОЗНИК“ 6, 8 һәм 10 да	БАЛТЫЙКЧЫЛАР
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7 һәм 9 да.	СЕНТЯБРЬДӘГЕ ТӨН

„СОЮЗКИШПРОДУКТ“ ның Татарстан бүлеге

Татарстан АССР ның барлык районнарында

ЭЧӘГЕЛӘР

(сыер, сарык, кәҗә, ат, дуңгыз эчәгеләре)

САТЫП АЛА

Эчәгеләрне „Союзкишпродукт“ ның җыючы-хәзерләүчеләре прейскурант бәясеннән алалар.

Гражданнар! Эчәгеләр—дәүләт промышленносты өчен кыйммәтле чимал. Эчәгеләрне ташламагыз һәм әрәм итмәгез, ә аларны „Союзкишпродукт“ ның хәзерләүчеләре аркылы дәүләткә сатыгыз.
2618—3—1